**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**Акбаш авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

№ 16 Акбаш ав. 28.10.2017 ел

*Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2008 елның 18 июлендә кабул ителгән «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы 18 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү (2008 елның 19 ноябрендәге 35 санлы, 2009 елның 26 июнендәге 11 санлы, 2011 елның 1 апрелендәге 8 санлы, 2011 елның 14 маендагы 12/1 санлы, 2012 елның 14 гыйнварындагы 1 санлы, 2012 елның 11 октябрендәге 20 санлы, 2013 елның 18 апрелендәге 10 санлы, 2013 елның 1 октябрендәге 16 санлы, 2013 елның 21 октябрендәге 17 санлы редакциясендә) хакында*

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ санлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, 2007 елның 17 декабрендәге «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы 722 санлы, 2017 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасының муниципаль хезмәткәрләренә муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, контроль-хисап органнары рәисләренең һәм айлык вазыйфаи затларының акчалата түләүләре күләмнәрен индексацияләү турында»гы 525 санлы карары нигезендә**,** Акбаш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Акбаш авыл җирлеге Советының 2008 елның 18 июлендәге "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында"гы 18 санлы карары кушымтасына (2008 елның 19 ноябрендәге 35 санлы, 2009 елның 26 июнендәге 11 санлы, 2011 елның 1 апрелендәге 8 санлы, 2011 елның 14 маендагы 12/1 санлы, 2012 елның 14 гыйнварындагы 1 санлы, 2012 елның 11 октябрендәге 20 санлы, 2013 елның 18 апрелендәге 10 санлы, 2013 елның 1 октябрендәге 16 санлы, 2013 елның 21 октябрендәге 17 санлы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

*1)* нигезләмәнең 1 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: « **Ютазы муниципаль районы**

Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары
хезмәткәрләренең, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы
вазыйфаи затларының, үз вәкаләтләрен даими
нигездә гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларының, җирле

үзидарә органнары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакындагы 1 кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫНЫҢ ЧИК КҮЛӘМНӘРЕ**

| **Вазыйфаларның атамасы** | **Айлык вазыйфаи оклад күләме (сум)** |
|---|---|
| ***Хезмәт өчен түләү төркеме (муниципаль берәмлек халкы санына карап)*** | ***12-нче төркем*** |
| | ***1,5 меңгә кадәр кеше*** |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) | 2889 |

*2)* 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: « **Ютазы муниципаль районы**

Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакындагы 2 кушымта

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНДӘ ҮЗ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ДАИМИ НИГЕЗДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК БАШЛЫГЫ, ДЕПУТАТЛАР, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ САЙЛАНУЛЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНА АКЧАЛАТА БҮЛӘКНЕҢ ИҢ ЧИК КҮЛӘМНӘРЕ**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

| **Вазыйфа исеме** | **Акчалата бүләк күләме ( сумнарда)** |
|---|---|
| ***Хезмәт өчен түләү төркеме (муниципаль берәмлек халкы санына карап)*** | ***12 нче төркем*** |
| | ***1,5 меңгә кадәр кеше*** |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 10262 |

*5)* 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: « **Ютазы муниципаль районы**

Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакындагы 3 кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ**

**ҖИРЛЕГЕНЕҢ БЮДЖЕТ ӨЛКӘСЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ БУЕНЧА БЕРДӘМ ТАРИФ ЧЕЛТӘРЕ КАГЫЛМЫЙ ТОРГАН БЮДЖЕТ ӨЛКӘСЕНЕҢ АЕРЫМ ОЕШМАЛАРЫ СТРУКТУР БҮЛЕКЧӘЛӘРЕ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ ҺӘМ БЕЛГЕЧЛӘРЕНЕҢ ЧИК ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ**

| **Вазыйфаларның атамасы** | **Айлык хезмәт хакы, сум** |
|---|---|
| Баш белгеч | 3622 |
| Хәрби исәп-хисап өстәле белгече | 952 |

**2.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет-финанс комиссиясенә йөкләргә.

**3.** Әлеге карар 2017 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Акбаш авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: Г.Ф.Хаҗиева